**РЕШЕНИЕ**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылы  торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

**12  ноябрь 2024 ел** **№ 15**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 12 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Урамнарны яктырту җайланмасы мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы  сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 501 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 327 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 291 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 36 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылы  торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Урамнарны яктырту җайланмасы мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә  Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Б. Храбров

Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы: И.Б. Храбров